**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Үчәлле авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Үчәлле авылы №64 "05" сентябрь 2022 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Үчәлле авыл җирлеге Советының 2019 елның 16 октябрендәге 155 номерлы "Азнакай муниципаль районы Үчәлле авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар пенсиясенә чыгуга бәйле рәвештә бер мәртәбә акчалата бүләкләү тәртибе һәм күләмнәре турында нигезләмә» карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Үчәлле авыл җирлеге муниципаль вазыйфаларын биләүче затлар пенсиясенә чыгуга бәйле рәвештә бер мәртәбә акчалата бүләкләү тәртибе һәм күләме турында нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

2013 елның 28 декабрендәге 400-ФЗ номерлы “Иминият пенсияләре турында”гы Федераль закон нигезендә

Үчәлле авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы _Үчәлле авыл җирлеге Советының 2019 елның 16 октябрендәге 155 номерлы "Азнакай муниципаль районы Үчәлле авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар пенсиясенә чыгуга бәйле рәвештә бер мәртәбә акчалата бүләкләү тәртибе һәм күләмнәре турында нигезләмә» карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Үчәлле авыл җирлеге муниципаль вазыйфаларын биләүче затлар пенсиясенә чыгуга бәйле рәвештә бер мәртәбә акчалата бүләкләү тәртибе һәм күләме турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1. 2.1 бүлекнең 2.1 пунктында беренче абзацта «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» 2001 елның 17 декабрендәге 173-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә картлык буенча хезмәт пенсиясе, яки инвалидлык буенча пенсия билгеләү» сүзләрен «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» 2013 елның 28 декабрендәге 400-ФЗ номерлы Федераль законның 8 статьясындагы 1 өлеше нигезендә картлык буенча хезмәт пенсиясе» сүзләренә алмаштырырга, яки картлык буенча вакытыннан алда яисә инвалидлык буенча иминият пенсиясе билгеләү)» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда түбәндәге веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация

челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга: http://aznakayevo.tatarstan.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис Г.М.Төхвәтуллина